# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасының Архив
фонды һәм архивлары турында

## I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

<u>1 статья.</u> Төп төшенчәләр

Әлеге Закон максатларында:

Татарстан Республикасының Архив фонды дип Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның матди һәм рухи тормышын чагылдыручы тарихи, фәнни, җәмгыяви, икътисади, сәяси һәм мәдәни әһәмияткә ия булган, Татарстан һәм Россия халыклары тарихи-мәдәни мирасының аерылгысыз өлешен тәшкил иткән документлар җыелмасы аңлашыла;

кемнеке булуына һәм мәгълүматның ни рәвешле теркәлүенә бәйсез рәвештә, җәмгыять өчен тарихи һәм гамәли әһәмияте аркасында саклана торган яки сакланырга тиешле документ һәм милекче өчен билгеле бер кыйммәткә ия документ архив документы дип атала;

үзара тарихи яки мантыйкый бәйләнгән архив документлары җыелмасы архив фонды дип атала;

архив документлары җыелмасын һәм шулай ук файдаланучылар мәнфәгатьләрендә архив документларын кабул итүне һәм саклауны гамәлгә ашыручы архив учреждениесе яки учреждениенең, оешманың яисә предприятиенең төзелмә бүлекчәсе архив дип атала;

халыкка күрсәтелми торган архив яшерен архив дип атала;

архив документларын җыюны, саклауны, исәпкә алуны һәм файдалануны оештыру эшчәнлеге архив эше дип атала;

документларны архивта, музейда, китапханәдә чикләнмәгән вакытта (мәңге) саклау архив документларын даими саклау дип атала;

документларны дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары,

дәүләт учреждениеләре, оешмалары, предприятиеләре тарафыннан оештырыла торган тиешле архивларда норматив-хокук актларында билгеләнгән чор дәвамында саклау архив документларын вакытлыча саклау дип атала;

документларны документларның ияse һәм архив, музей, китапханә арасындагы килешүдә (шартнамәдә) каралган шартларда, милекченең архив документларына милек хокукы сакланган килеш, архивта, музейда, китапханәдә саклау архив документларын кире кайтарып алу хокукы белән саклау дип атала.

<u>2 статья.</u> Әлеге Законны куллану өлкәсе

Әлеге Закон архивларны һәм архив фондларын туплау, аларны саклауны, исәпкә алуны, файдалануны оештыру һәм архив документларының саклануын тәэмин итү, аларны гражданнар, җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләрендә файдалану максатларында алар белән идарә итү мөнәсәбәтләрен җайга сала.

<u>3 статья.</u> Татарстан Республикасының Архив фонды һәм архивлар турында законнар

Татарстан Республикасының Архив фонды һәм архивлар турында законнары әлеге Законнан һәм Татарстан Республикасының Архив фонды һәм архивлары белән бәйле мәсьәләләргә кагылышлы башка закон актларыннан гыйбарәт.

<u>4 статья.</u> Архив эше буенча Татарстан Республикасының вәкаләтләре

Татарстан Республикасы, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм әлеге Закон нигезендә Россия Федерациясе генә хәл итүче һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы уртак мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе вәкаләтләренә керүче мәсьәләләрдән кала, архив эшенә караган барлык мәсьәләләрне мөстәкыйль хәл итә.

## II бүлек. Татарстан Республикасының Архив фонды

5 статья. Татарстан Республикасы Архив фондының составы

Татарстан Республикасы Архив фонды составына, ничек барлыкка килүенә, иясе кем булуына, кайда саклануына һәм милекнең рәвешенә карамастан, Татарстан Республикасы территориясендәге архив фондлары һәм архив документлары керә. Документларны Татарстан Республикасының Архив фондына кертү билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының архив эше идарәсе органнары һәм архив учреждениеләре тарафыннан аларның кыйммәтен ачыклау нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасының Архив фонды дәүләтнеке булган һәм дәүләтнеке булмаган өлешләрдән тора.

6 статья. Татарстан Республикасы Архив фондының дәүләтнеке булган һәм дәүләтнеке булмаган өлешләре

Татарстан Республикасы Архив фондының дәүләтнеке булган өлешен Татарстан Республикасының дәүләт (республика һәм коммуналь) милкендәге, Татарстан Республикасы территориясендәге федераль милектәге архив фондлары һәм архив документлары тәшкил итә.

Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының республика милкенә караган учреждениеләрнең, оешмаларның һәм предприятиеләрнең эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән һәм барлыкка килүче архив фондлары, архив документлары, шулай ук хокукый һәм физик затларнын законда каралган тәртиптә республика фондына керүче архив фондлары һәм архив документлары, шул исәптән чит илләрдән дә, республика милкенә керә.

Дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары һәм коммуналь милеккә караган идарәләр, учреждениеләр, оешмалар һәм предприятиеләр эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән һәм барлыкка килүче архив фондлары һәм архив документлары, шулай ук хокукый һәм физик затларның законда каралган тәртиптә, шул исәптән чит илләрдән дә, коммуналь милеккә тапшырылган архив фондлары һәм архив документлары коммуналь милеккә керә.

Татарстан Республикасы Архив фондынын дәүләтнеке булмаган өлешен тарихи, фәнни, җәмгыяви, икътисади, сәяси һәм мәдәни кыйммәткә ия булган һәм җирле үзидарә милкендәге, җәмәгать

берләшмәләре һәм оешмалары милкендәге, шулай ук диннең дәүләттән аерылган вакытыннан Татарстан Республикасы территориясендә эшли торган дини берләшмәләр һәм оешмалар милкендәге яисә шәхси милектәге архив фондлары һәм архив документлары тәшкил итә.

## Ш бүлек. Татарстан Республикасында архивлар

7 статья. Архивларны төзү

Татарстан Республикасының хокукый һәм физик затларына архив төзү хокукы гарантияләнә.

Татарстан Республикасы Архив фондының дәүләтнеке булган өлеше документларыннан, шулай ук билгеләнгән тәртиптә аеруча кыйммәтле һәм бик сирәк очрый торганнар рәтенә кертелгән документлардан яшерен архивлар яисә гражданнарның хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы яшерен архивлар төзү тыела.

8 статья. Архивларга, архив учреждениеләре бүлмәләренә һәм биналарына милек хокукын тапшыру

Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге архив фондларына һәм архив документларына милек хокукын башка затларга тапшыру Татарстан Республикасы законнары билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы территориясендәге федераль милек булган архив фондларына һәм архив документларына милек хокукын башка затларга тапшыру Россия Федерациясе законнары билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Архив фондының дәүләтнеке булган өлешенә керә торган архив фондларын һәм архив документларын, шулай ук алар урнашкан бүлмәләрне һәм биналарны дәүләт милкеннән фәкать суд карары нигезендә генә чыгарып була. Дәүләт предприятиеләре хосусыйлаштырылган очракта аларның эшләү дәверендә барлыкка килгән архив фондлары һәм архив документлары, кайда саклануларына карамастан, Татарстан Республикасы Архив фондының дәүләтнеке булган өлешендә кала.

Татарстан Республикасы Архив фондының дәүләтнеке булмаган өлешендәге документларның ияләре үзләренең документларын Татарстан Республикасының дәүләт милкенә тапшырырга мөмкин. Бу очракта документка милек хокукын тапшыру килешү (шартнамә) ни-

нигезендә рәсмиләштерелә.

Дәүләтнеке булмаган берләшмәләр, учреждениеләр, оешмалар һәм предприятиеләр ябылган яки хокукый һәм законлы варислары булмыйча ияләре үлеп киткән очракларда Татарстан Республикасы Архив фондының дәүләтнеке булмаган өлешенә караган документлар Татарстан Республикасының дәүләт милкенә керәләр һәм даими саклау өчен Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе системасындагы архив учреждениеләренә тапшырылалар.

9 статья. Архивларга милек хокукын яклау

Милек рәвешенә карамастан, архивларга милек хокукы законнар белән яклана. Милек иясенең яки ул вәкаләт биргән органның яисә затның ризалыгыннан башка бер генә архив документы да тартып алынырга тиеш түгел, ул фәкать суд карары нигезендә генә алынырга мөмкин.

Законсыз рәвештә биләнүче архивлар, архив фондлары һәм архив документлары закон нигезендә үз хуҗаларына тапшырылалар.

## IV бүлек. Татарстан Республикасында архив эше белән дәүләтнең идарә итүе

10 статья. Татарстан Республикасында архив эше белән дәүләтнең идарә итүе

Татарстан Республикасында архив эше белән дәүләтнең идарә итүе Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан, архив эшенә идарә итү буенча ул төзегән орган - Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе аша гамәлгә ашырыла.

11 статья. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе системасының архив органнарын һәм учреждениеләрен финанс һәм матди-техник тәэмин итү

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе системасының архив органнарын һәм учреждениелә-

рен финанс һәм матди-техник тәэмин итү Татарстан Республикасының Республика бюджеты, җирле бюджетлар, шулай ук бюджеттан тыш акчалар исәбенә башкарыла.

Татарстан Республикасының мөстәкыйль балансга булган һәм хокукый зат хокукына ия архив учреждениеләренә һәм аларның бүлекчәләренә, аларның уставта каралган, эшкуарлыкка бәйле булмаган эшчәнлеге өлешендә, салым салуда законнарда каралган тәртиптә ташламалар ясалырга мөмкин.

Дәүләт хакимиятенең һәм идарәсенең җирле органнары һәм идарәләре тиешле архив органнарын һәм учреждениеләрен Татарстан Республикасы Архив фондының документларны саклауга билгеләгән таләпләренә җавап бирүче биналар һәм корылмалар белән тәэмин итә.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе тарафыннан үз системасындагы органнарга һәм учреждениеләргә оператив идарә итүгә тапшырылучы яки аларда булган мөлкәт, шул исәптән күчемсез дә, алар карамагына даими биләү, файдалану һәм идарә итү хокукы белән беркетелә.

Архив органнарына һәм учреждениеләренә беркетелгән мөлкәт, шул исәптән оператив идарә итүгә тапшырылучы яки аларда булган күчемсез мөлкәт милекчеләренә бу мөлкәтне алу яисә башка хокукый һәм физик затларга яңадан бүлү тыела.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе системасы архив органнары һәм учреждениеләре биләгән җир кишәрлекләре аларга даими файдалануга бирелә.

## 12 статья. Дәүләтнеке булмаган архивларга дәүләт кайгыртуы

Татарстан Республикасы Архив фондының дәүләтнеке булмаган өлешенә караган документлар хуҗаларының үтенече буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе системасындагы архив органнары һәм учреждениеләре аларның архивларын саклауда, туплауда һәм файдалануда методик ярдәм күрсәтәләр. Татарстан Республикасы Архив фондының дәүләтнеке булмаган өлеше документлары хуҗалары белән килешеп, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе системасының архив органнары һәм учреждениеләре дәүләтнеке булмаган архивларга башка төрле, шул исәптән финанс ярдәме, күрсәтергә мөмкин.

Татарстан Республикасы Архив фонды составына карый торган дәүләтнеке булмаган архивлар һәм архив документлары аларны архив органнарында, учреждениеләрендә, дәүләт музейларында һәм китапханәләрендә кире кайтарып алу шартларында саклау хокукына, аларның страховой күчермәләрен булдыру, шулай ук аларны торгызу һәм файдалану хокукына ия.

<u>13 статья.</u> Әлеге Законның үтәлешенә дәүләт тикшерүе

Әлеге Законның үтәлешенә дәүләт тикшерүе дәүләт органнары, шул исәптән архив эшенә идарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

<u>14 статья.</u> Иҗтимагый һәм дини берләшмәләрнең һәм оешмаларның архив эшен үстерүдә катнашуы

Әлеге Законга, Татарстан Республикасының башка закон чыгару актларына нигезләнеп, иҗтимагый һәм дини берләшмәләр һәм оешмалар архив эшен үстерү һәм камилләштерү бурычларын хәл итүдә булышлык күрсәтергә мөмкин.

**V бүлек. Архив документларын саклау, туплау, исәпкә алу һәм файдалану**

<u>15 статья.</u> Татарстан Республикасының Архив фонды документларын саклауны тәэмин итүдә милекчеләрнең бурычлары

Татарстан Республикасының Архив фонды составына кергән документларның хуҗалары аларның саклануын тәэмин итәргә тиешләр.

Аеруча кыйммәтле һәм сирәк очрый торган архив документлары махсус саклана һәм файдаланыла. Бу документларның страховой күчермәләре ясала.

Архив докуметларын аеруча кыйммәтле һәм сирәк очрый торганнар рәтенә кертүне, шулай ук страховой күчермәләр ясауны һәм саклауны билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе системасына кергән архив органнары һәм учреждениеләре гамәлгә ашыра.

Дәүләт органнары, дәүләт учреждениеләре, оешмалары һәм

предприятиеләре Татарстан Республикасы Архив фондының дәүләтнеке булган өлешенә керүче документларны саклауны, исәпкә алуны, сайлауны, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Архив идарәсе системасына караган архив органнары һәм шулай ук Россиянең Дәүләт архив хезмәте дәүләт стандартлары, кагыйдәләре һәм күрсәтмәләре нигезендә даими саклауга тапшыру өчен әзерләүне тәэмин итәләр; Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе белән килештереп, тиешле архивларның эшчәнлеген билгели торган норматив һәм ысулый документлар эшлиләр һәм раслыйлар.

Дәүләт органнары, дәүләт учреждениеләре, оешмалары һәм предприятиеләре. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең экспертиза-тикшерү һәм ысулый комиссиясе, даими саклана торган эшләрнең тасвирламасын раслаганга һәм шәхси составның эшләре буенча тасвирламаларны килештергәнгә кадәр, саклау вакыты чыккан документларны юк итә алмыйлар.

Татарстан Республикасы Архив фондының дәүләтнеке булмаган өлешенә караган документларның хуҗалары, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе системасына кергән архив органнары һәм учреждениеләре белән килештерми торып, бу документларны юк итә алмыйлар.

**16 статья.** Татарстан Республикасы Архив фондының дәүләтнеке булган өлеше документларын саклау

Татарстан Республикасы Архив фондының дәүләтнеке булган өлешенә караган документларны даими саклауны архив учреждениеләре, дәүләт музейлары һәм китапханәләре гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы Архив фондының дәүләтнеке булган өлешенә караган документларны вакытлыча саклауны дәүләт органнары, дәүләт учреждениеләре, оешмалары һәм предприятиеләре үзләре төзи торган тиешле архивларда гамәлгә ашыралар, аларны документларны саклау буенча билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган бинадар белән тәэмин итәләр.

Татарстан Республикасы Архив фондының дәүләтнеке булган өлешенә караган документларны даими һәм вакытлыча саклау һәм күрсәтелгән документларны архив учреждениеләренә даими саклауга тапшыру тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе тарафыннан билгеләнә.

17 статья. Архивларны, музейларны һәм китапханәләрне Татарстан Республикасы Архив фонды документлары белән комплектлау

Архив учреждениеләре Татарстан Республикасының дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт учреждениеләре, оешмалары һәм предприятиеләре эшчәнлегендә барлыкка килгән архив документларыннан, законда каралган тәртиптә башка хокукый һәм физик затлардан алынган архив документларыннан туплана.

Дәүләт музейларын һәм китапханәләрен, шулай ук җәмәгать, дини берләшмәләрне һәм оешмаларны, шәхси архивларны Татарстан Республикасы Архив фондының дәүләтнеке булган өлешендә саклан-ган документларның төп нөсхәләре белән комплектлау тыела. Кире кайтарып алу шарты белән сакларга бирелгән архив документлары, хуҗалары аларны саклау хакында килешүне вакытында озайтмаган һәм күрсәтелгән документларны архив учреждениесенә, дәүләт музеена һәм китапханәсенә тапшырылган көннән алып 100 ел дәвамында таләп итмәгән очракта, алар дәүләт милкенә күчә.

Татарстан Республикасы Архив фондының дәүләтнеке булмаган өлешенә караган документлар сатылган очракта, дәүләт аларны өстенлекле шартларда сатып алырга хокуклы. Документларның ияләре, сатуны оештыручылар, сату буласы көнгә 15 көннән дә соңга калмыйча, сатуның төгәл вакытын һәм урынын күрсәтеп, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенә язмача хәбәр итәргә тиеш.

18 статья. Татарстан Республикасы Архив фонды документларын дәүләт тарафыннан исәпкә алу

Татарстан Республикасы Архив фондының дәүләтнеке булган һәм дәүләтнеке булмаган өлешләренә караган барлык документлар, кайда саклануларына, ияләре кем булуга, мәгълүматның ни рәвештә һәм нинди техника белән беркетелүенә карамастан, дәүләт тарафыннан исәпкә алынырга тиешләр. Татарстан Республикасы Архив фонды документларын дәүләт тарафыннан исәпкә алу билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе, аның архив органнары һәм учреждениеләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

19 статья. Архив документларыннан файдалану

Татарстан Республикасы Архив фондының дәүләтнеке булган өлешенә караган документлар һәм аларга белешмәләр файдалану өчен барлык хокукый һәм физик затларга бирелә.

Татарстан Республикасының архив учреждениеләрендә архив документларыннан файдалану тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе тарафыннан билгеләнә.

Татарстан Республикасы Архив фондының дәүләтнеке булган өлешенә караган, дәүләт музейларында һәм китапханәләрендә даими саклапган, вакытлыча дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында, дәүләт учреждениеләрендә, оешмаларында, предприятиеләрендә саклапган документларны файдалану тәртибе, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе белән килештереп, аларның үзләре тарафыннан билгеләнә.

Җәмәгать һәм дини берләшмәләр һәм оешмалар милкендәге яисә шәхси милектәге архив документларын файдалану фәкать милекчеиең ризалыгы белән генә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасының архив учреждениеләре, файдаланучыларга архив документларының күчермәләрен һәм күрсәтелгән документларның белешмәләрен коммерция максатларында файдалану өчен биргәндә, алардан файдалану шартларын да билгеләргә хаклы.

Татарстан Республикасы Архив фондының дәүләтнеке булган өлешенә караган, дәүләт серенә яки закон тарафыннан саклана торган башка сергә ия документларны файдалану, әгәр законда башкача билгеләнгән булмаса, алар барлыкка килгән көннән соң 30 ел узгач рөхсәт ителә.

Гражданнарның шәхси тормышлары хакында мәгълүматлар булган, шулай ук аларның тормышына куркыныч тудырган һәм торак иминлеген бозарга мөмкин архив документларын файдалануда чикләүләр, әгәр законда башкача каралмаса, документ барлыкка килгән көннән 75 ел итеп билгеләнә. Шушы вакытка кадәр, бу документ белән танышу өчен рөхсәтне граждан үзе, ә ул вафат булганнан соң - аның варислары бирергә тиеш.

Документларның бөтен килеш саклануына куркыныч янамаганда, хокукый һәм физик затлар архив белешмәләре, архив учреждениеләрендә, дәүләт музейларында һәм китапханәләрендә, дәүләт учреждениеләренең, оешмаларының һәм предприятиеләренең архив-

ларында саклanучы архив документларының расланган күчермәләрен һәм архив документлары өземтәләрен алырга яисә күчереп алырга хокуклы.

Хокукый һәм физик затлар архив документларыннан файдаланган өчен һәм аларның саклanышы өчен законнарда билгеләнгән тәртиптә җавап бирәләр. Хокукый һәм физик затлар күрсәтелгән документларны файдалану мәсьәләләре буенча архив эше белән идарә итү органнарының һәм архив учреждениеләренең карарларына шикаять белдерә яисә закон нигезендә судка яки буйсыну тәртибендә югарырак торган архив эшенә идарә итү органнарына мөрәҗәгать итә алалар.

## VI бүлек. "Татарстан Республикасының Архив фонды һәм архивлары турында" Татарстан Республикасы Законын бозган өчен җаваплылык

20 статья. "Татарстан Республикасының Архив фонды һәм архивлары турында" Татарстан Республикасы Законын бозган өчен җаваплылык

Татарстан Республикасының урындагы затлары һәм гражданнары, Татарстан Республикасы территориясендәге чит ил гражданнары һәм гражданлыклары булмаган затлар әлеге Законны бозган өчен законнарда билгеләнгән тәртиптә хокукый җаваплылыкка тартылалар.

21 статья. Әлеге Законны бозу аркасында китерелгән зыянны каплау

Хокукый һәм физик затлар Татарстан Республикасының Архив фонды документларына үзләре китергән зыянны законнарда билгеләнгән тәртиптә капларга тиешләр.

## VII бүлек. Халыкара хезмәттәшлек

22 статья. Архив эше өлкәсендә халыкара хезмәттәшлек

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе системасының архив органнары һәм учреждениеләре, дәүләт музейлары һәм китапханәләре, хокукый һәм физик затлар -

архив документларының ияләре архив эше өлкәсендә халыкара хезмәттәшлектә, архив мәсьәләләре буенча халыкара киңәшмәләрдә һәм конференцияләрдә катнашалар.

23 статья. Архив документларын Татарстан Республикасыннан читкә алып чыгу

Татарстан Республикасы Архив фондының дәүләтнеке булган өлешенә караган архив документларын, шулай ук дәүләтнеке булмаган өлешенә караган һәм бетен халык байлыгы саналган сирәк очрый торган һәм аеруча кыйммәтле документларны, шушы статьяның икенче өлешендә каралган очраклардан кала, Татарстан Республикасыннан читкә алып чыгу тыела.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе Татарстан Республикасы Архив фондының дәүләтнеке булган өлешенә караган документларны вакытлыча һәм дәүләтнеке булмаган өлешенә караган сирәк очрый торган һәм аеруча кыйммәтле документларны законнар нигезендә алдан килешенгән чорга Татарстан Республикасыннан читкә алып чыгарга рөхсәт бирергә хокуклы.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенә кирәк булган очракта Татарстан Республикасыннан читкә чыгарыла торган архив документларының күчермәләрен алу хокукы бирелә.

24 статья. Архив документларының күчермәләрен читкә чыгару һәм читтән кертү

Сатып алу, сату, бүләк итү яисә,милекченең башка төрле гражданлык - хокукый гамәлләрне башкаруы нәтиҗәсендә алынганнарны да кертеп, архив документлары күчермәләрен (төп нөсхә хокукында булмаганнарны) һәм аларның өземтәләрен Татарстан Республикасыннан читкә чыгару һәм Татарстан Республикасына кертү, ябык архив документлары күчермәләреннән һәм аларның өземтәләреннән кала, чикләүсез гамәлгә ашырылырга мөмкин.

25 статья. Халыкара шартнамәләр

Татарстан Республикасы катнашындагы халыкара шартнамәләрдә Татарстан Республикасының Архив фонды һәм архивлары турында Татарстан Республикасы законнарында каралганнан үзгә кагыйдәләр билгеләнсә, халыкара шартнамә кагыйдәләре кулланыла.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре.
1996 елның 13 июне
N 644

3 tat1.txt